РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14.03.2018 № 277-п

Төзелешкә, объектны файдалануга тапшыруга, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләүгә һәм бирүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 27 июлендәге 880 номерлы карарына таянып, “Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм раслау турында” Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 30 гыйнварындагы 78-п номерлы карарына һәм Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә ведомствоара хезмәттәшлекнең технологик карталарын карау һәм раслау тәртибенә нигезләнеп

КАРАР БИРӘ:

**1.** Кушымталарны расларга:

**1.1.** Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

**1.2.** Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

**1.3.** Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (20 нче кушымта);

**2.** Үз көчен югалткан дип танырга:

– «Шәһәр төзелеше, торак мөнәсәбәтләре, икътисад һәм мәдәният өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 22 июлендәге 1001-п номерлы җитәкчесе карарының 1.6; 1.7; 1.11 пунктлары;

– «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы муниципаль районы башкарма комитетының 2016 елның 26 гыйнварындагы 88 номерлы карарының 47, 47.1, 47.3, 48.1,

48.2, 48.3, 55.1, 55.2, 55.3 пунктлары.

– «Капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәт бирү, реконструкцияләү, объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы муниципаль районы башкарма комитетының 2017елның 30 декабрендәге 1511-п номерлы карары.

**3.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль районының
Башкарма комитеты
Җитәкче М.Р. Ишниязов